**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

29.03.2018 № 215

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 ел, 30 сентябрь, 892 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Социаль тәэмин итүнең Бердәм дәүләт мәгълүмат системасы төбәк сегментын камилләштерү максатында

КАРАР БИРӘМ:

1. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында” 2013 елның 30 сентябрендә кабул ителгән 892 нче карары 1 нче пунктын түбәндәге подпунктлар белән тулыландырырга:

“1.1. Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләвеннән өлешчә яки тулысынча азат ителү турында мәгълүмат социаль тәэмин итүнең Бердәм дәүләт мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә һәм социаль тәэмин итүнең Бердәм дәүләт мәгълүмат системасы операторы тарафыннан билгеләнгән форматлар нигезендә урнаштырылырга тиеш.

1.2. Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләвеннән өлешчә яки тулысынча азат ителү турында мәгълүмат Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә һәм социаль тәэмин итүнең Бердәм дәүләт мәгълүмат системасы операторы тарафыннан билгеләнгән форматлар нигезендә социаль тәэмин итүнең Бердәм дәүләт мәгълүмат системасын куллану аша алынырга мөмкин”.

2. Бу карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Башкарма комитет җитәкчесенең иҗтимагый-мәдәни үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.С. Әхмәтшин